Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

___16.02.2026______

Менделеевск шәһәре

№ __101_____

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль контракт нигезендә социаль ярдәм күрсәтү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 1682 номерлы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 16 апрелендәге 256 номерлы, 2024 елның 10 декабрендәге 1125 номерлы, 2025 елның 16 маендагы 331 номерлы карарлары редакциясендә) карарына нигезләнеп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан федераль бюджеттан финанслау шартларында, федераль закон белән билгеләнмәгән өлешендә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1931 номерлы (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 29 декабрендәге 2191 номерлы карары редакциясендә) карарына туры китереп, авыр тормыш хәлендә калган кешеләргә адреслы социаль ярдәм формаларының нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 2 сентябрендәге 550 номерлы карарының 1 пункты үз көчендә түгел дип санарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Исхаков

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 18 февралендәге
101 номерлы карарына
кушымта

Социаль контракт нигезендә
дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча
ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Рәис: | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Рәис урынбасары | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад, алгарышлы социаль икътисадый үсеш территориясен һәм эшкуарлыкны үстерү буенча урынбасары |
| Секретарь: | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге консультанты (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары: | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад, сәнәгать һәм эшмәкәрлеккә ярдәм бүлеге башлыгы |
| | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы "Өмет яры" халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге" дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлеге мөдире (килешү буенча) |
| | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы |
| | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар һәм сәүдә бүлеге башлыгы урынбасары |

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча)

Менделеевск районы буенча «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге башлыгы (килешү буенча)

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча)

"Менделеевск үзәк район хатаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча)

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы"Өмет яры" халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге" дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе директоры (килешү буенча)

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы "Өмет яры" халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге" дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең гаиләгә һәм балаларга ярдәм бүлеге буенча социаль хезмәт белгече (килешү буенча)

Татарстан Республикасы буенча "Ватанны саклаучылар" махсус хәрби операциясендә катнашучыларны дәүләт ярдәм фонды филиалының Менделеевск районында социаль координаторы (килешү буенча)